# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Татар Борнашы авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2024 елның 30 ноябреннән №1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Татар Борнашы торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елда Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Татар Борнашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, моңа түбәндәгеләр керми: СВО катнашучысы һәм аларның гаилә әгъзалары -100%; 1 төркем инвалидлар, күп балалы гаиләләр; уку йортлары студентлары; тыл хезмәтчәннәре-50 %.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Татар Борнашы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Борнаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районы
Борнаш авыл җирлеге башлыгы С. В. Бурукин